ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ЗАИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

08.02.2024 г. Заинск № 68

**Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 августындагы 662 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Социаль яклау дәрәҗәсен күтәрүгә юнәлдерелгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына социаль ярдәм чараларын күрү максатында һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Уставының 45 статьясына таянып, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитеты

**карар бирә:**

1. Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы Башкарма комитетының 2023 елның 25 августындагы 662 номерлы «Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районы гомуми белем бирү оешмалары укучыларының туклануын оештыру тәртибе турындагы Нигезләмәне раслау турында» карарына кушымтаны 1.4 пункты белән тулыландырып, түбәндәге эчтәлектәге үзгәрешләр кертергә:
- «1.4. Дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында мәгълүмат социаль өлкәдә Бердәм цифрлы платформада (алга таба – БЦП) Россия Федерациясе Хөкүмәте билгеләгән тәртиптә һәм күләмдә, БЦП операторы билгеләгән форматларга ярашлы рәвештә урнаштырыла.».
2. Әлеге карар рәсми рәвештә басылып чыккан көннән үз көченә керә.
3. Әлеге карарны массакүләм мәгълүмат чараларында «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында», веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

**Башкарма комитет җитәкчес** **Э.Э. Галеев**

Э.Р. Сафаргалиев
3-27-42